МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

**от «20» февраля 2017** **№ 57_**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү, рөхсәтне гамәлдә булуы вакытыннан алда туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләт хезмәтләре һәм мунииципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” №210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хәкимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 880 номерлы карары нигезендә, боерык бирәм:

1. Әлеге Боерыкка кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү, рөхсәтне гамәлдә булуы вакытыннан алда туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчләрен югалткан дип санарга:

“Административ регламентны раслау турында” 2013 елның 7 маендагы 84 номерлы боерыгы;

“Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 07.05.2013 ел, №84 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу

эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында” 2014 елның 7 июлендәге 213 номерлы боерыгы.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Транспорт идарәсе башлыгы А.В. Сидоровка йөкләргә.

Минист вазыйфаларын башкаручы А.Н. Усманов

Татарстан Республикасы
транспорт һәм юл
хуҗалыгы министрлыгының
2017 елның 20 февралендәге
57 номерлы боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү, рөхсәтне гамәлдә булуы вакытыннан алда туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Регламент Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү һәм аны гамәлдә булуы вакытыннан алда туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар: юридик затлар һәм хосусый эшмәкәрләр, физик затлар (рөхсәтнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, рөхсәт алынган транспорт чарасы хуҗасы) (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында (алга таба – Министрлык) күрсәтелә.

1.3.1.Министрлыкның урнашу урыны: Казан ш., Н.Ершов ур., 13а й.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән тыш, көн саен. Дүшәмбе-пәнҗешәмбе 8.30 дан 17.30 сәгатькәчә; җомга – 8.30 дан 16.15 сәгатькәчә. Төшке аш вакыты – 12.00 дән 12.45 сәгатькәчә.

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәтләр бирү һәм аларны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү турында гаризаларны һәм аларга кушып бирелә торган документларны тапшыру графигы: сишәмбе, җомга 8.30 дан 12.00 сәгатькәчә.

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга рөхсәт алу өчен тәкъдим ителгән транспорт чараларын карау графигы: сишәмбе, җомга 10.00 һәм 11.00 сәгатьләрдә.

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәтләр бирү, яңадан рәсмиләштерелгән рөхсәтләр бирү графигы: чәршәмбе, җомга 10.00 дән 12.00 сәгатькәчә.

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәтләр дубликатларын бирү графигы: чәршәмбе, җомга 10.00 дән 12.00 сәгатькәчә.

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында гариза һәм аңа кушымта итеп бирелә торган документларны кабул итү графигы: сишәмбе 8.30 – 16.00, җомга 8.30 – 15.00 сәгатьләрдә.

Җәмәгать транспортында “Кооператив институты” тукталышына кадәр барырга:

– № 1, 10, 10а, 18, 19, 25, 35, 35а, 55, 63,71, 93 автобуслар белән;

– № 2, 7, троллейбуслар белән;

– № 4 трамвай белән.

Керү – пропуск һәм (яки) шәхесне раслаучы документ белән.

Зоналар буенча бүлү схемасы нигезендә, Татарстан Республикасы 11 муниципаль берәмлегендә гаризалар кабул итү һәм рөхсәтләр бирү буенча өстәмә район пунктлары (алга таба – район пункты) оештырылган (№ 1 кушымта).

1.3.2. Министрлыкның Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлегенең (алга таба – бүлек) белешмәләр алу өчен телефоннары: 291-90-22, 291-91-14.

1.3.3. Министрлыкның “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – “Интернет” челтәре) рәсми сайты: http://www.mindortrans.tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Министрлык бүлмәләрендә мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен урнаштырылган, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматлардан торучы дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмати стендлар аша;

2) “Интернет” челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.mindortrans.tatar.ru.).

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatar.ru) (алга таба – Портал);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (вазыйфалар) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә);

1.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүматны Бүлек белгече Министрлыкның рәсми сайтына һәм Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмати стендларга урнаштыра.

Мәгълүмат стендларына урнаштырыла торган хәбәрләрдә 1.3.1., 2.1., 2.3., 2.4., 2.5., 2.8., 2.10., 2.11., 5.1. пунктларда күрсәтелгән дәүләт хезмәтләре турында белешмәләр урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге законнар һәм норматив-хокукый актлар нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясе Салым кодексы (алга таба – РФ СК) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2000, № 32, 3340 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2010, №31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясенең кайбер законнар актларына үзгәрешләр кертү турында” 21 апрель, 2011 ел, № 69-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 69-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы,2011 ел, № 17, 2310 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының “Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (алга таба – Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы) (Россия Федерациясе законнар җыелмасы, 2012, № 19, 2338 ст.);

“Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү турында” 10 октябрь, 2011 ел, № 77 ТРЗ Татарстан Республикасы законы (алга таба – № 77-ТРЗ ТР закон) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10, 1219 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре” 06.07.2005, № 317 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Министрлык турында нигезләмә) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 27.07.2005, № 28, 0646 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 880 ТР МК карар) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 08.12.2010, №46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү турында” 10 октябрь, 2011 ел, № 77-ТРЗ Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында” 06.12.2011 ел, № 999 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү тәртибе (димәк, алга таба – № 999 ТР МК карары, Тәртип) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре, республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары” журналы, 2012, № 3, 0077 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт һәм аның дубликатын бирүгә түләү билгеләү тәртибе турында” 28.01.2013 ел, № 34 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 34 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре, республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары” журналы, 2013, № 12, 0425 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт һәм аның дубликатын бирү (яңадан рәсмиләштерү) өчен түләү күләмен билгеләү турында” 31.01.2013 ел, № 7-1/т Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карары (алга таба – ТР Тарифлар буенча дәүләт комитеты карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре, республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары” журналы, 2013, № 40, 1253 ст.).

1.5.Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

җиңел такси – фрахтование килешүе нигезендә пассажирлар һәм багаж йөртү өчен файдаланыла торган “М1” категориясендә транспорт чарасы;

йөртүче – җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү хезмәте күрсәтү эшчәнлеген алып баручы юридик зат яки хосусый эшмәкәр;

“М1” категориясендәге транспорт чарасы – пассажирлар йөртү өчен файдаланыла торган һәм, шофер урыныннан тыш, күп дигәндә – сигез урынлы транспорт чарасы.

техник хата – дәүләт хезмәтләре күрсәтелгәндә Министрлык тарафыннан җибәрелгән, документларга кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең нәтиҗәсе) бу белешмәләр нигезләнә торган документлардагы мәгълүматка туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, хәреф хатасы, грамматик яисә арифметик хата);

күпфункцияле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү үзәгенең аерымланган эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документлар кабул итү, гариза бирүчеләргә консультация бирү урыны (аерымланган эш урыны).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтләре күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәтләре күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү аңлашыла. Гариза стандарт бланкта тутырыла.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпләр атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1.Дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү, рөхсәтне (алга таба – рөхсәт) гамәлдә булуы вакытыннан алда туктату | № 69-ФЗ Федераль законның 9 ст.;<br>№ 77-ТРЗ ТР Законының 3 ст.;<br>Тәртип;<br>Министрлык турында нигезләмә |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | № 999 ТР МК карарының 1 п.;<br>Министрлык турында нигезләмәнең 3.1 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | 1. Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт.<br>2 Рөхсәт дубликаты.<br>3. Яңадан рәсмиләштерелгән рөхсәт.<br>4. Рөхсәтне гамәлдә булуы вакытыннан алда туктату.<br>5. Рөхсәт бирүдән, аны яңадан рәсмиләштерүдән һәм аны гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатудан баш тарту.<br>Рөхсәт җиңел такси сыйфатында файдаланыла торган һәр транспорт чарасына 5 (биш) елга бирелә.<br>Рөхсәт, Министрлык бланкында рәсмиләштерелә (№ 999 ТР МК карары белән расланган форма буенча). | № 69-ФЗ Федераль законның 9 ст.,<br>№ 77-ТРЗ ТР Законының 3 ст.;<br>Тәртипнең 1.4., 1.6., 3.3. пп. |

| | | |
|---|---|---|
| | Рөхсәт дубликаты рөхсәт бланкында “дубликат” һәм “рөхсәтнең төп нөсхәсе гамәлдә түгел дип танылa” дигән билгеләр-сүзләр белән рәсмиләштерелә. | |
| 2.4. Дәүләт хезмәтләре күрсәтү срогы (дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү вакыты исәпкә алынырга тиеш),<br>дәүләт хезмәтләре күрсәтүне туктатып тору срогы (дәүләт хезмәтләре күрсәтүне туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда) | Гаризаны теркәүгә алганнан соң дүрт көн эчендә бирелә[1].<br>Рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү гариза теркәлгәннән соң дүрт көн эчендә хәл ителә.<br>Рөхсәт дубликатын бирү гариза теркәлгәннән соң дүрт көн эчендә хәл ителә.<br>Рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату гариза теркәлгән вакыттан алып өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Рөхсәт бирүдән баш тарту гариза теркәлгән вакыттан алып дүрт көн эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Рөхсәтне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту гариза теркәлгән вакыттан алып өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Рөхсәт бирүне вакытыннан алда туктатудан баш тарту гариза теркәлгә вакыттан алып өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәтләре күрсәтү срокларын туктатып тору каралмаган. | № 69-ФЗ Федераль законның 9ст.;<br>№ 999 ТР МК карары<br>Тәртипнең 1.6., 2.5, 3.1, 3.4, 4.3, 5.7, 5.8, 5.11 пп. |

**[1] Бу регламентта алга таба процедуралар озынлыгы эш көннәрендә исәпләнә.**

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә зарури һәм мәҗбүри башка хезмәтләр күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле кирәкле документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүченең аларны, шул исәптән электрон рәвештә, алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе. | 1. Рөхсәт алу өчен тапшырырга кирәк:<br>а) Рөхсәт бирү турында гариза, гариза түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:<br>– юридик затлар өчен – тулы (булган очракта) һәм кыскартылган атамасы, шул исәптән фирма атамасы һәм юридик затның оештыру-хокукый формасы, урнашу урыны адресы, юридик затны оештыру турында язуның дәүләт теркәү номеры, юридик затның юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү фактын раслаучы документ мәгълүматлары, дәүләт теркәвен хәл итүче органның урнашу урыны адресын, шулай ук телефон номерын, юридик затның электрон почта адресы (№ 999 ТР МК карары белән расланган форма буенча);<br>– хосусый эшмәкәрләр өчен – фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны буенча теркәлү адресы, шәхесен раслаучы документ мәгълүматлары, хосусый эшмәкәрне дәүләт теркәвенә алу турында язуның дәүләт теркәү номеры, хосусый эшмәкәр турында мәгълүматларны хосусый эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрына кертү фактын раслаучы документ мәгълүматлары, дәүләт теркәвенә алуны хәл итүче органның урнашу урынын, адресын, шулай ук хосусый эшмәкәрнең телефон номерын | № 69-ФЗ Федераль законның 9 ст., 1-3, 2 өлеше;<br>№ 77-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы;<br>№ 880 ТР МК карары<br>Тәртипнең 1.6, 2.1, 2.2, 4.1, 4.2, 5.2-5.5 пп. |

| | | |
|---|---|---|
| | һәм электрон почта адресын (булган очракта) күрсәтеп (№ 999 ТР МК карары белән расланган форма буенча);<br>– салым түләүченең идентификация номеры һәм салым түләүченең салым органында учетка кую турында документ мәгълүматлары;<br>б) мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиле) шәхесен раслаучы документ күчермәсе;<br>в) җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү хезмәте күрсәтү өчен файдалану күздә тотылган транспорт чарасын теркәү турында таныклык күчермәсе, юридик зат (юридик затлар) җитәкчесе яки хосусый эшмәкәр (хосусый эшмәкәрләр өчен) раслаган;<br>г) лизинг килешүе күчермәсе (җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү хезмәте күрсәтү өчен файдалану күздә тотылган транспорт чарасына лизинг килешүе шартларында транспорт чарасына ия булган очракта), юридик зат (юридик затлар өчен) җитәкчесе яки хосусый эшмәкәр (хосусый эшмәкәрләр өчен) раслаган;<br>яки аренда килешүе күчермәсе (җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү хезмәте күрсәтү өчен файдалану күздә тотылган транспорт чарасына аренда килешүе шартларында транспорт чарасына ия булган очракта), юридик зат җитәкчесе (юридик затлар өчен) яки | |

| | | |
|---|---|---|
| | хосусый эшмәкәр (хосусый эшмәкәрләр өчен) раслаган;<br>яисә нотариуста раслаган ышанычнамә күчермәсе җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү хезмәте күрсәтү өчен хосусый эшмәкәр белән файдалану күздә тотылган транспорт чарасы белән идарә итү хокукына (транспорт чарасы физик затның транспорт чарасы белән идарә итү хокукына нотариуста расланган ышанычнамәсе нигезендә бирелгән очракта).<br>2. Рөхсәт дубликатын алу өчен тапшырырга кирәк:<br>а) юридик затлар өчен (№ 999 ТР МК карары белән расланган форма буенча) яки хосусый эшмәкәрләр өчен (№ 999 ТР МК карары белән расланган форма буенча) рөхсәт дубликатын бирү турында гариза;<br>б) мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиле) шәхесен раслаучы документ күчермәсе;<br>в) рөхсәт кәгазен бозу-ерту очрагында рөхсәт дубликатын бирү турындагы гаризага бозылган рөхсәт бланкы кушып бирелә.<br>3. Рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү өчен тапшырырга кирәк:<br>а) юридик затлар өчен (№ 999 ТР МК карары белән расланган форма буенча) яки хосусый эшмәкәрләр өчен (№ 999 ТР МК карары белән расланган форма | |

| | | |
|---|---|---|
| | буенча) рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү турында гариза, анда түбәндәге яңа мәгълүматлар булырга тиеш:<br>бу Регламентның 2.5 пунктының бер өлешендәге “а” пунктчасындагы күздә тотылганча мөрәҗәгать итүче яки аның хокукый дәвамчысы (юридик затны үзгәртеп кору очрагында);<br>– юридик зат атамасы яки аның урнашу урыны (юридик зат атамасын яки урнашу урынын үзгәртү очрагында);<br>– хосусый эшмәкәрнең яшәү урыны, фамилиясе, исеме, атасының исеме, шәхесен раслаучы документ мәгълүматлары (хосусый эшмәкәрнең яшәү урыны, фамилиясе, исеме, атасының исеме, шәхесен раслаучы документ мәгълүматлары үзгәргән очракта);<br>– җиңел такси сыйфатында файдаланыла торган транспорт чарасының яңа дәүләт теркәлү билгесе (җиңел такси сыйфатында файдаланыла торган транспорт чарасының дәүләт теркәү билгесе үзгәртелгән очракта);<br>б) мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиле) шәхесен раслаучы документ күчермәсе;<br>в) җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү хезмәте күрсәтү өчен файдалану күздә тотылган транспорт чарасының теркәүгә алуы турында таныклык күчермәсе, юридик зат җитәкчесе | |

| | | |
|---|---|---|
| | (юридик затлар өчен) һәм хосусый эшмәкәр (хосусый эшмәкәрләр өчен) раслаган;<br>г) гамәлдәге рөхсәтнең төп нөсхәсе;<br>д) лизинг килешүе күчермәсе (җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү хезмәте күрсәтү өчен файдалану күздә тотылган транспорт чарасына лизинг килешүе шартларында транспорт чарасына ия булган очракта), юридик зат (юридик затлар өчен) җитәкчесе яки хосусый эшмәкәр (хосусый эшмәкәрләр өчен) раслаган;<br>яки аренда килешүе күчермәсе (җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү хезмәте күрсәтү өчен файдалану күздә тотылган транспорт чарасына аренда килешүе шартларында транспорт чарасына ия булган очракта), юридик зат җитәкчесе (юридик затлар өчен) яки хосусый эшмәкәр (хосусый эшмәкәрләр өчен) раслаган;<br>яисә нотариуста раслаган ышанычнамә күчермәсе җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү хезмәте күрсәтү өчен файдалану күздә тотылган транспорт чарасы белән идарә итү хокукына (транспорт чарасы физик затның транспорт чарасы белән идарә итү хокукына нотариуста расланган ышанычнамәсе нигезендә бирелгән очракта).<br>4. Рөхсәтнең гамәлдә булуын | |

| | | |
|---|---|---|
| | вакытыннан алда туктату өчен түбәндәгеләрне тапшырырга кирәк:<br>а) рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында гариза (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 999 номерлы карары белән расланган форма буенча);<br>б) мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ (мөрәҗәгать итүче вәкил аша эш йөрткән очракта) (хосусый эшмәкәрләр яисә юридик затлар өчен);<br>в) транспорт чарасын теркәү турындагы таныклыкның расланган күчермәсе (транспорт чарасы хуҗасы булган физик затлар өчен).<br>Дәүләт хезмәтләреннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән килеп алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган.<br><br>Гариза һәм аңа кушымта итеп бирелә торган материаллар тапшырылуы турында хәбәр итәлә торган заказлы почта элемтәсе белән кәгазь чыганакларда йә Портал аша электрон рәвештә мөрәҗәгать итүче (яисә аның законлы вәкиле) тарафыннан турыдан-туры Министрлыкка китерелә (җибәрелә).<br>Гаризаны тапшырган вакытта яисә | |

| | | |
|---|---|---|
| | заказлы почта элемтәсе белән җибәргәндә мөрәҗәгать итүче тарафыннан танықланган документлар гаризага кушымта итеп бирелә.<br>Гаризаны электрон рәвештә тапшырганда кирәкле документларның сканер аша чыгарылган күчермәләре кушымта итеп бирелә. | |
| 2.6. Дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрнең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар саклана торган дәүләт | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>1. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (Россия Федераль салым хезмәтенең Ведомствоара электрон хезмәттәшлек бердәм системасында).<br>2. Хосусый эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (Россия Федераль салым хезмәтенең Ведомствоара электрон хезмәттәшлек | № 210-ФЗ Федераль закон<br>№ 880 ТР МК карары |

| | | |
|---|---|---|
| органы, җирле үзидарә органы йә оешма. | бердәм системасында).<br>3. Дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы түләүне раслый торган акчалар керү турында мәгълүматлар (Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсендә).<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле документларны алуның әлеге Регламентның 2.5. пунктында билгеләнгән ысуллары һәм тәртибе.<br>Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда саналган документларны таләп итү тыела. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актларда күздә тотылган очракларда килештерергә тиешле (бу эшне дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы хәл итә) дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур подразделениеләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Бу Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән зат дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткәндә.<br>2. № 999 ТР МК карары белән расланган формага туры килмәгән гариза тапшырганда.<br>3. Мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда таләп ителә торган мәгълүматлар булмаганда. | № 69-ФЗ Федераль законның 9 ст.;<br>№ 77-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы;<br>Тәртипнең 1.6., 2.5 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | 4. Бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тулысынча тапшырмаганда.<br>5. Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт алу өчен белдерелгән транспорт чаралары законда билгеләнгән техник таләпләргә туры килмәгәндә.<br>6. Дөрес язылмаган гариза тапшыру.<br>7. Вәкаләт бирелмәгән юридик зат яисә хосусый эшмәкәр тарафыннан гариза бирү. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Рөхсәт бирүдән һәм рөхсәтне яңадан рәсмиләштерүдән баш тартуга нигез булып мөрәҗәгать итүченең ялган мәгълүматлар тапшыруы тора;<br>Рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктатудан баш тарту өчен нигезләр:<br>күрсәтелгән рөхсәт үзенә бирелмәгән хосусый эшмәкәр яисә юридик зат тарафыннан гариза тапшыру;<br>әзерләнгән рөхсәтне алмыйча калдыру.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга нигезләр билгеләнмәгән. | № 69-ФЗ Федераль законның 9 ст.;<br>№ 77-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы;<br>Тәртипнең 1.6., 3.6 п. |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү (яңадан рәсмиләштерү) өчен түләү күләме 400 сум тәшкил итә. | № 69-ФЗ Федераль законның 9 ст.;<br>№ 77-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 8 ст.;<br>ТР Тарифлар буенча дәүләт комитеты карары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының № 34 карары. |

| | | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл кылуга рөхсәт дубликатын бирү өчен түләү 200 сум тәшкил итә. | |
| 2.11.Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләргә түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтүне тәкъдим итү таләп ителми. | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы |
| 2.12.Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос тапшырганда һәм мондый хезмәт күрсәтүләрнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Кәгазьдә рөхсәт алу өчен гариза тапшыру вакыты, чират булганда – 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш. Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросын теркәү срогы, шулай ук электрон формада | Министрлыкка гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләр өчен көтеп тору урыннарына һәм аларны кабул итү урыннарына, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә бу объектлардан инвалидларның | Кабул итү урыны тәэмин ителгән:<br>һава җилләткеч система;<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз;<br>мәгълүмат стендлары;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт интеграцияләнгән телекоммуникацияләр | № 880 ТР МК карары |

| | | |
|---|---|---|
| файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә, дәүләт хезмәтләре күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы, мультимедия мәгълүматын урнаштыруга һәм аның бизәлешенә таләпләр | системасына тоташтырылган мәгълүмати киоск.<br>Дәүләт хезмәтләре күрсәтү урыннарына инвалидларга керү өчен тоткарлыксыз шартлар тәэмин ителә (бинага тоткарлыксыз керү-чыгу юллары һәм бинада хәрәкәт итү мөмкинлекләре).<br>Дәүләт хезмәтләре күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы, мультимедия мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, җайлы урыннарда урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтләреннән һәркемнең файдалана алуы һәм аның сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән, дәүләт хезмәтләре күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара эшчәнлеге һәм аның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтләрен күпфункцияле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү үзәгендә, күпфункцияле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү үзәгенең аерымланган эш урынында күрсәтү мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәтләре күрсәтү барышы турында, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып мәгълүмат алу мөмкинлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып тора:<br>1) Министрлыкның җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашуы;<br>2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен белгечләрнең тиешле санда булуы;<br>3) гаризаларны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;<br>4) мөрәҗәгать итүче гаризаны № 1 кушымтада күрсәтелгән район пунктларында тапшыру мөмкинлегенә ия.<br>5) инвалидларга дәүләт хезмәтләреннән башка затлар белән беррәттән файдаланырга комачаулый торган кыенлыкларны җиңәргә булышу;<br>6) дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм срогы турында Министрлыкның Интернет челтәрендәге | |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында тулы мәгълүмат урнаштырылган булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:<br>1) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлек итү очраулары саны һәм аларның дәвамлылыгы;<br>2) документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;<br>3) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>4) дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт хезмәткәрләре гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләр булмау;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт хезмәткәрләренең мөрәҗәгать итүчеләргә карата игътибарсызлыгына, әдәпсезлегенә шикаятьләр булмау (шикаятьләрнең Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затлары санына карата нисбәте).<br>Мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән үзара эшчәнлеге күләме:<br>дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар тапшырганда һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда – иң күбе ике тапкыр (консультацияләр моңа керми);<br>гаризаны һәм документларны почта аша | |

| | | |
|---|---|---|
| | җибәргәндә – иң күбе бер тапкыр (консультацияләр моңа керми);<br>портал аша гариза биргәндә – иң күбе бер тапкыр (консультацияләр моңа керми).<br>Мөрәҗәгать итүче белән үзара эшчәнлек дәвамлылыгы – иң күбе 15 минут.<br>Дәүләт хезмәтләре күпфункцияле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү үзәгендә, күпфункцияле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү үзәгенең аерымланган эш урынында күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына урнаштырыла. | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре. | Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны Портал (https://uslugi.tatar.ru./taxi_license/application) аша электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге бар. | |

## 3. Административ процедураларның составы, тәртибе һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү үзәгендә, күпфункцияле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү үзәгенең аерымланган эш урынында үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

3.1.1. Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл кылуга рөхсәт бирү һәм рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү, эшчәнлекне хәл кылуга рөхсәт дубликатын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү;

2) мөрәҗәгатьне кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запрослар булдырып, аларны дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж алып бару эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү, рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү (рөхсәт бирүдән, рөхсәтне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту) турында боерык әзерләп чыгару;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелегенең блок-схемасы № 2 кушымтада китерелә.

### 3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү

Мөрәҗәгать итүче Бүлеккә яйсә шәхсән райондагы пункт белгеченә телефон аша һәм (яки )электрон почта аша дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече, райондагы пункт белгече мөрәҗәгать итүчегә тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультация бирә, дәүләт хезмәтләре күрсәтү турында гариза бланкы бирә һәм кирәк булган очракта гариза бланкын тутырырга булыша.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне хәл ителә (мөрәҗәгать итүче шәхсән яйсә телефон аша мөрәҗәгать иткән очракта) яки мөрәҗәгать кергәннән көннән алып дүрт эш көне эчендә (мөрәҗәгать итүче почта аша һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать иткән очракта).

Процедуралар нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы ягыннан һәм рөхсәт алуга кагылышлы башка мәсьәләләр буенча консультацияләр һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү.

3.3. Татарстан Республикасы территориясендә пассажирлар һәм багаж алып бару эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) шәхсән кәгазьдә, Портал аша электрон рәвештә яки почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән), бу Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән кушымта белән гаризаны Бүлеккә яки район пункты белгеченә тапшыра.

Электрон рәвештә гариза тапшырганда, соралган документларның сканерланган күчермәләре, гаризаны заказлы хат белән почта аша җибәргәндә – мөрәҗәгать итүче раслаган документлар кушып бирелә.

3.3.2. Гаризаны район пунктына тапшырганда район пункты белгече (алга таба – вәкаләтле хезмәткәр):

гаризаны һәм документларны кабул итә;

тикшерә:

– документларның тулысынча тапшырылу-тапшырылмавын;

– гаризадагы мәгълүматларның (гариза формасы нигезендә гаризада күрсәтелергә тиешле) тулы булу-булмавын;

– тапшырылган гаризадагы мәгълүматларның тапшырылган документлардагы мәгълүматларга туры килү-килмәвен;

Портал аша, тиешле формалар нигезендә, гаризадагы һәм аңа кушып бирелгән документлардагы мәгълүматларны электрон рәвештә китерә.

Вәкаләтле хезмәткәр бу Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булмаганда, гаризаны гаризаларны теркәүгә алу журналында терки, гаризаны тапшыру ысулына бәйле рәвештә, мөрәҗәгать итүчегә почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән ) яки электрон рәвештә, рөхсәт бирү турында гаризаны һәм аңа кушып бирелгән документларны кабул итү датасы турында билге белән, документлар исемлеге күчермәсен тапшыра яки җибәрә һәм мөрәҗәгать итүченең гаризасын һәм документларын Министрлыкка, карар кабул итү өчен, Портал аша электрон рәвештә җибәрә.

Вәкаләтле хезмәткәр, бу Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булган очракта, шәхсән үзе яки телефон аша мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең булуын җиткерә һәм аңа документларны кире кайтарып бирә.

Мөрәҗәгать итүче таләбе белән, документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә, мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту (баш тартуның нигезле сәбәпләрен күрсәтеп һәм мондый тартуга нигез булып торучы норматив-хокукый актлар һәм башка документлар нигезләмәләрен күрсәтеп) почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) уведомление җибәрә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза һәм докуменларны кабул итү, теркәү һәм Министрлыкка җибәрү яки документларга мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару.

3.3.3. Гаризаны турыдан-туры Министрлыкка тапшыру очрагында, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчедән шәхсән кәгазьдә, Портал аша электрон рәвештә яки почта аша заказлы хат белән гариза кергәндә түбәндәгеләрне хәл итә:

гаризаны һәм документларны кабул итә;

тикшерә:

– документларның тулы булу-булмавын;

– гаризаның тулысынча тутырылу-тутырылмавын, гариза формасы нигезендә гаризада күрсәтелергә тиешле мәгълүматларның булу-булмавын;

– тапшырылган гаризада күрсәтелгән мәгълүматларның тапшырылган документлардагы мәгълүматларга туры килү-килмәвен;

Формалар нигезендә, гаризадагы һәм аңа кушып бирелгән документлардагы мәгълүматларны Портал аша электрон рәвештә күчерә.

Бүлек белгече гаризада һәм документларда бу Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең булу-булмавына тикшерә.

Бүлек белгече бу Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булмаганда, гаризаны гаризаларны теркәү журналына терки, мөрәҗәгать итүчегә почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) яки электрон рәвештә, гаризаны тапшыру ысулына бәйле рәвештә, рөхсәт бирү турындагы гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны кабул итү датасы турында билге белән документлар исемлеге күчермәсен бирә яки җибәрә, шуннан соң бу Регламентның 3.3.6 пунктында күздә тотылган процедуралар хәл ителә.

Бүлек белгече бу Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булган очракта:

мөрәҗәгать итүче гаризаны тапшырганда, шәхсән яки телефон аша аңа гаризасын теркәүгә комачаулыкларның булуы турында җиткерә һәм документларны кире кайтара. Мөрәҗәгать итүче таләбе белән баш тарту турында карар кабул иткәннән соң өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында уведомление, баш тартуның нигезле сәбәпләрен күрсәтеп һәм баш тартуга нигез булып торган норматив-хокукый актлар һәм башка документлар нигезләмәләрен күрсәтеп тапшыра яки аңа заказлы хат белән почта аша (тапшыру турында уведомление белән җибәрә);

мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм документларны электрон рәвештә яки почта аша җибәргәндә, мөрәҗәгать итүче таләбе белән, баш тарту турында карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә, баш тартуның нигезле сәбәпләрен күрсәтеп һәм баш тартуга нигез булып торган норматив-хокукый актлар һәм башка документлар нигезләмәләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында уведомление тапшыра яки почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) җибәрә.

Гариза район пунктыннан алынганда, бу Регламентның 3.3.6 пункты белән каралган процедуралар хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: гаризаны һәм документларны кабул итү, теркәү; мөрәҗәгать итүчегә документларны яки гаризаны кабул итүдән баш тарту, баш

тартуның нигезле сәбәпләрен һәм конкрет норматив-хокукый актларны күрсәтеп, турында уведомление проекты министрга (вәкаләтлесе) имза салуга җибәрү (гаризаны тапшыру ысулына бәйле рәвештә).

3.3.4. Министр (вәкаләтлесе), баш тартуның нигезле сәбәпләрен күрсәтеп һәм конкрет норматив-хокукый актларга нигезләнеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында уведомлениене имзалый һәм Бүлек белгеченә җибәрә.

Процедура нәтиҗәсе: баш тартуның нигезле сәбәпләрен күрсәтеп һәм конкрет норматив-хокукый актларга нигезләнеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында уведомление имзалау.

3.3.5. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, баш тартуның нигезләнгән сәбәпләрен күрсәтеп һәм баш тартуга нигез булып торучы норматив-хокукый актлар һәм башка документлар нигезләмәләрен күрсәтеп, почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) яки электрон рәвештә (гаризаны тапшыру ысулына бәйле рәвештә) документларны кабул итүдән баш тарту турында уведомление җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура министр (вәкаләтлесе) хатны имзалаганнан соң бер көн эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: баш тартуның нигезләнгән сәбәпләрен күрсәтеп һәм конкрет-норматив хокукый актларга таянып, мөрәҗәгать итүчегә гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту турында уведомление җибәрү.

Мөрәҗәгать итүче документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең ачыклануы язмача бәян ителгән уведомление алган очракта, документларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып торган сәбәпне юкка чыгаргач, бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документларны яңадан тапшыра ала.

3.3.6. Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне соратып ала:

мөрәҗәгать итүченең хосусый эшмәкәр яисә юридик зат буларак статусы турында;

дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы түләүне раслый торган акчалар керү турында.

Әлеге Регламентның, 3.3.3, 3.3.6 пунктларында билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәләре: ЕГРЮЛ йә ЕГРИП белешмәләре, дәүләт пошлинасы түләүне раслый торган акчалар керү турында белешмәләр.

3.3.7. Бүлек белгече алынган мәгълүматлар нигезендә:

рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

рөхсәт бирү турында боерык проектын яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерык проектын һәм, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, уведомление әзерли;

рөхсәт бирү турында боерык проектын яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерык проектын һәм рөхсәт бирүдән баш тарту турында уведомление проектын министрга (вәкаләтлесе) имза салуга җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар алдагы процедура беткән вакыттан алып бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: проектларны министрга (вәкаләтлесе) имза салуга җибәрү.

3.3.8. Министр (вәкаләтлесе) рөхсәт бирү турында боерыкны яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерыкны һәм рөхсәт бирүдән баш тарту турында уведомление имзалый. Имзаланган документлар Бүлек белгеченә җибәрелә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура проектлар министрга (вәкаләтлесе) имза салуга алынган көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: рөхсәт бирү турында боерыкны яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерыкны һәм рөхсәт бирүдән баш тарту турында уведомление имзалау.

3.3.9. Бүлек белгече:

рөхсәт бирү турында боерыкны (рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерыкны һәм, баш тартуның нигезле сәбәпләрен күрсәтеп, рөхсәт бирүдән баш тарту турында имзаланган уведомлениене), теркәүгә алу өчен, документлар әйләнеше бүлегенә тапшыра;

кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә нинди дә булса ысул белән хәбәр итә;

рөхсәт бирүдән баш тарту яисә рөхсәт бирү турында Порталның чикләнгән контурында мәгълүмат урнаштыра;

рөхсәт кәгазе әзерли.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәү өчен документлар әйләнеше бүлегенә тапшырылган документлар, әзерләнгән рөхсәт кәгазе.

3.3.10. Документлар әйләнеше бүлеге белгече рөхсәт бирү турында боерыкның яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерыкны һәм, баш тартуның нигезле сәбәпләрен күрсәтеп, рөхсәт бирүдән баш тарту турында имзаланган уведомление терки.

Рөхсәт бирү турында гариза район пункты аша алынган очракта, Бүлек белгече рөхсәт бирү турында боерыкны яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында уведомлениене электрон элемтә чаралары аша, мөрәҗәгать итүчегә тапшыру өчен, район пунктына җибәрә. Вәкаләтле хезмәткәр рөхсәт бирү турында боерык нигезендә мөрәҗәгать итүчегә тапшыру өчен рөхсәт хәзерли.

Процедураның нәтиҗәсе: район пунктына җибәрелгән теркәлгән документлар (гариза район пункты аша кергән очракта).

3.3.11. Рөхсәт бирү турындагы боерык нигезендә вәкаләтле хезмәткәр аны мөрәҗәгать итүчегә тапшыру өчен рөхсәт кәгазе әзерли.

3.3.10-3.3.12 пунктларында билгеләнелә торган процедуралар документларга министр (вәкаләтлесе) имза салган көннән бер эш көн эчендә хәл ителә.

Процедураның нәтиҗәсе: әзерләнгән рөхсәт кәгазе

3.3.12. Документлар әйләнеше бүлеге белгече, гариза тапшыру җаена карап, мөрәҗәгать итүче таләбе буенча, мөрәҗәгать итүчегә гаризада курсәтелгән адрес буенча почта аша заказлы хат белән, тапшыру турында хәбәрнамә белән, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, рөхсәт бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә җибәрә.

Бу пункт белән билгеләнелә торган процедуралар, баш тарту турында хәбәрнамә теркәлгәннән соң ике эш көне эчендә хәл ителә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә рөхсәт бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә яки электрон рәвештә урнаштырылган хәбәрнамә.

3.3.13. Бүлек белгече (вәкаләтле хезмәткәр) рөхсәт алу өчен китерелгән транспорт чарасының законнардагы мәҗбүри таләпләргә туры килүен тикшерә, гаризага кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләрен оригиналлары белән чагыштыра, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) рәсмиләштерелгән рөхсәтне тапшыра. Мөрәҗәгать итүче бирелгән рөхсәтләрне теркәү журналына рөхсәт алу турында имза куя.

Процедураларның нәтиҗәсе: тикшерелгән транспорт чарасы, документларның чагыштырылган оригиналлары һәм күчермәләре, тапшырылган рөхсәт.

3.3.14. Бүлек белгече:

Порталның чикләнгән контурында рөхсәт алу турындагы гаризаның статусын үзгәртә;

рөхсәт бирү эшен формалаштыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүчегә рөхсәт бирелгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гаризаның статусын актуальләштерү; формалаштырылган рөхсәт бирү эше.

3.3.12. Бүлек белгече:

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә бирелгән рөхсәтләр Реестрын (алга таба – Бирелгән рөхсәтләр реестры) чыгара һәм мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат секторы жибэрэ.

Мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат секторы белгече, Министрлыкның “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтына Бирелгән рөхсәтләр реестрын урнаштырып, бирелгән рөхсәтләр турындагы белешмәләрне яңарта.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар Порталның чикләнгән контурында рөхсәт бирү турындагы гаризаның статусы үзгәртелгән көннән алып биш көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: яңартылган Бирелгән рөхсәтләр реестры.

3.4. Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә бирелгән рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү

3.4.1. Мөрәҗәгать итүче (вәкиле) түбәндәге очракларда:

юридик зат үзгәртеп оештырылганда;

юридик затның атамасы, урнашу урыны үзгәргәндә;

хосусый эшмәкәрнең яшәү урыны, исеме, фамилиясе һәм атасының исеме (булган очракта), шәхесен раслаучы документ мәгълүматлары үзгәргәндә;

җиңел такси сыйфатында файдаланыла торган транспорт чарасының дәүләт теркәү билгесе үзгәргәндә, шәхсән кәгазьдә, электрон рәвештә Портал аша яки почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) бу

Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә бирелгән рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү турында гаризаны һәм аңа кушылып бирелә торган документларны Бүлеккә яисә район пунктының вәкаләтле хезмәткәренә тапшыра (җибәрә).

3.4.2. Рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү турында гаризаны кабул итү, теркәү, бу Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең булу-булмавын ачыклау өчен документларны тикшерү бу Регламентның 3.3.2 яки 3.3.3 пункты нигезендә хәл ителә.

3.4.3. Ведомствоара оешмаларга запрослар җибәрү һәм алардан җаваплар алу бу Регламентның 3.3.6 пункты нигезендә хәл ителә.

3.4.5. Бүлек белгече алынган мәгълүматлар нигезендә: мөрәҗәгать итүче тапшырган гаризаны һәм документларны карап тикшерә, аның рөхсәт делосында урын алган мөрәҗәгать итүче турында мәгълүматлардан чыгып;

әлеге гаризада һәм аңа кушып бирелгән документлардагы мәгълүматларның дөреслеген тикшерә;

рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү яки аны яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар кабул итә;

рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү турында боерык проектын яки рөхсәтне яңадан рәсмиләтерүдән баш тарту турында боерык проектын һәм баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, уведомление әзерли;

боерык проектын министрга (вәкаләтлесе) раслауга җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар алдагы процедура беткән вакыттан алып бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: документлар проектларын министры) вәкаләтлесе) имза салуга җибәрү.

3.4.5. Министр (вәкаләтлесе) рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү яки рөхсәтне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында боерыкны һәм рөхсәтне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту уведомлениене имзалый һәм Бүлек белгеченә җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура документлар имзалауга алынган көнне хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү яки рөхсәтне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында боерыкны һәм баш тарту турында уведомлениене имзалау.

3.4.6. Бүлек белгече:

Рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү турында боерыкны (рөхсәтне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында боерыкны һәм, баш тартуның нигезле сәбәпләрен күрсәтеп, рөхсәтне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында имзаланган уведомлениене) документлар әйләнеше бүлегенә теркәүгә тапшыра.

Яңадан рәсмиләштерелгән рөхсәт кәгазен әзерли.

Рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү турында гариза район пункты аша алынган очракта, Бүлек белгече, теркәгәннән соң, рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү турында боерыкны яки рөхсәтне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында уведомлениене электрон элемтә чаралары аша район пунктына җибәрә. Вәкаләтле хезмәткәр

рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү турында боерык нигезендә, мөрәҗәгать итүчегә тапшыру өчен яңадан рәсмиләштерелгән рөхсәт кәгазен әзерли.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура министр (вәкаләтлесе) документларны имзалаган көннән соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү турында боерыкны (рөхсәтне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында боерык һәм, баш тартуның нигезле сәбәпләрен күрсәтеп, рөхсәтне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында имзаланган уведомление) теркәү, яңадан рәсмиләштерелгән рөхсәт кәгазен әзерләү.

3.4.7. Бүлек белгече (вәкаләтле хезмәткәр), мөрәҗәгать итүче элек бирелгән рөхсәтне кире кайтару шарты белән, мөрәҗәгать итүчегә яңадан рәсмиләштерелгән рөхсәтне тапшыра, мөрәҗәгать итүче рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү турындагы гаризага кушымта итеп бирелгән документларның оригиналларын яисә мондый документларның нотариус тарафыннан таныкланган күчермәләрен күрсәтергә һәм бирелгән рөхсәтләр журналында имза куярга тиеш.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: яңадан рәсмиләштерелгән рөхсәтне бирү яки, 3.3.12 пункт нигезендә баш тарту турында уведомление җибәрү.

3.4.8. Бирелгән рөхсәтләр реестры статусын үзгәртү һәм аны яңарту әлеге Регламентның 3.3.14 һәм 3.3.15 пунктчалары нигезендә башкарыла.

3.5. Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт дубликатын бирү

3.5.1. Мөрәҗәгать итүче Портал аша электрон рәвештә, шәхсән кәгазьдә яки почта аша (почта аша заказлы хат белән, тапшыру турында уведомление белән). Рөхсәт кәгазен югалту яки бозуга (рөхсәтне кушымта итеп биреп) бәйле рәвештә рөхсәт дубликатын бирү турында гаризаны, мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документ күчермәләре белән бергә Бүлеккә яки вәкаләтле хезмәткәргә җибәрә.

3.5.2. Рөхсәт дубликатын бирү турында гаризаны кабул итү, теркәү, бу Регламентның 2.8. пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең булу-булмавын ачыклау өчен документларны тикшерү 3.3.2 яки 3.3.3 пунктлары нигезендә хәл ителә. 2.8 пунктта күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булмаганда, бу Регламентның 3.3.6 пунктында күздә тотылган процедуралар үткәрелә.

3.5.3. Ведомствоара оешмаларга запрослар җибәрү һәм алардан җаваплар алу бу Регламентның 3.3.6 пункты нигезендә хәл ителә.

3.5.4. Бүлек белгече:

рөхсәт дубликатын бирү турында боерык проектын әзерли;

әзерләнгән докумиентлар проектын министрга (вәкаләтлесе) имза салуга җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар алдагы процедура беткән вакыттан алып бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: документлар проектларын министрга (вәкаләтлесе) имза салуга җибәрү.

3.5.5. Министр (вәкаләтлесе) рөхсәт дубликатын бирү турында боерык әзерли. Имза салынган боерык Бүлек белгеченә җибәрелә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура документлар имза салуга алынганнан көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: имза салынган документлар.

3.5.6. Бүлек белгече:

гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында җиткерә;

“дубликат” һәм “рөхсәтнең төп нөсхәсе гамәлдә түгел дип танылa” дигән язу-билгеләр белән рөхсәт дубликатын әзерли;

Дубликатны бирү турында гариза район пункты аша алынган очракта Бүлек белгече рөхсәт дубликаты бирү турында боерыкны вәкаләтле хезмәткәргә җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар алдагы процедура беткән вакыттан алып бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында уведомление җиткерү.

3.5.7. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиле) шәхесен раслаучы документның төп нөсхәсен карагач рөхсәт дубликатын алу турында бирелгән рөхсәтләр журналына имза салдырып рөхсәт дубликатын мөрәҗәгать итүчегә бирә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көнне хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: рөхсәт дубликатын бирү.

3.5.8. Бирелгән рөхсәтләр реестры статусын үзгәртү һәм аны яңарту әлеге Регламентның 3.3.14 һәм 3.3.15 пунктчалары нигезендә башкарыла.

3.6. Рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату.

3.6.1. Мөрәҗәгать итүче рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турындагы гаризаны кәгазь саклагычта яисә почта аша (тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы почта элемтәсе белән) шәхсән үзе Бүлеккә, вәкаләтле хезмәткәргә, күпфункцияле үзәккә яисә аерымланган эш урынына җибәрә.

3.6.2. Рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турындагы гаризаны кабул итү, теркәү, документларны кабул итүдән баш тартуның әлеге регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләре булу-булмауны тикшерү әлеге Регламентның 3.3.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6.3. Бүлек белгече рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында боерык проектын әзерли һәм аны раслау өчен министрга (ул вәкаләт биргән затка) тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында раслау өчен министрга (ул вәкаләт биргән затка) тапшырылган боерык проекты.

3.6.4. Министр (ул вәкаләт биргән зат) рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турындагы боерыкны раслый. Имзаланган документлар Бүлек белгеченә тапшырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында имза куелган боерык.

Әлеге Регламентның 3.6.3 һәм 3.6.4 пунктларында билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән алып бер көн эчендә башкарыла.

3.6.5. Бүлек белгече рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турындагы боерыкны теркәү өчен документлар әйләнеше бүлегенә тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: документлар әйләнеше бүлегенә тапшырылган документлар.

3.6.6. Документлар әйләнеше бүлеге белгече рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турындагы боерыкны терки.

Әлеге Регламентның 3.6.5 – 3.6.6 пунктларында билгеләнгән процедуралар боерыкка министр (ул вәкаләт биргән зат) тарафыннан имза салынган көннән алып бер көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында теркәлгән боерык.

3.6.7. Бирелгән рөхсәтләр реестрын актуальләштерү һәм яңарту әлеге Регламентның 3.3.14 һәм 3.3.15 пунктчалары нигезендә башкарыла.

3.7. Дәүләт хезмәтләрен күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең аерымланган эш урыны аша күрсәтү.

3.7.1. Дәүләт хезмәтләре күпфункцияле үзәк, аерымланган эш урыны аша күрсәтелми.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең нәтиҗәсе булып санала торган документта техник хата табылган очракта, мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) Бүлеккә шәхсән үзе кәгазь саклагычларда йә тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы почта элемтәсе аша түбәндәгеләрне җибәрә:

техник хатаны төзәтү турында гариза;

техник хаталы тапшырылган рөхсәт;

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ;

мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ.

Алынган рөхсәттә табылган хатаны төзәтү турындагы гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь саклагычларда йә тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы почта элемтәсе аша җибәрелә, техник хата табылган рөхсәт гаризага кушымта итеп бирелә.

3.8.2. Министрлыкның документлар әйләнеше бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итеп ала, кушымта итеп бирелгән документлары

белән бергә аны электрон документлар әйләнеше системасында терки һәм Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында теркәлгән һәм Бүлеккә тапшырылган гариза.

3.8.3. Техник хатаны төзәтү турында гариза кергән очракта, Бүлек белгече Министрлыкта булган документларны чагыштыра һәм, техник хата булуы расланса, рөхсәтне әзерли һәм аны алу мөмкинлекләре турында мөрәҗәгать итүчегә теләсә нинди юллар белән хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура техник хата турында гариза Бүлек белгеченә карауга кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: яңадан ясалган рөхсәт һәм мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

3.8.4. Бүлек белгече тапшырылган рөхсәттә техник хата барлыгын ачыклаган очракта, Министрлыкта булган документлар чагыштырыла һәм, техник хата барлыгы расланса, рөхсәт яңадан ясала, техник хата җибәрелгән рөхсәтне кире тапшырып, яңасын алу зарурлыгы турында теләсә нинди юллар белән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура техник хата табылган көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: әзерләнгән рөхсәт һәм мөрәҗәгать итүчегә хәбәрнамә җибәрү.

3.8.5. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) рөхсәтне тапшыра, мөрәҗәгать итүче аны алу турында имза куя.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган рөхсәт.

Район пунктында бирелгән рөхсәттәге техник хаталарны төзәтү процедурасы рөхсәтнең оригиналын бирү урынында әлеге Регламентның 3.8.1 – 3.8.5 пунктлары нигезендә башкарыла.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфатына контрольлек итү үз эченә ала: мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозуларны ачыклау һәм бозу сәбәпләрен юкка чыгару, шикаятьләрне карап тикшерү, мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгате буенча тикшерүләр үткәрү, алар буенча карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләү, Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмау) карата карарлар әзерләү.

Административ процедураларның үтәлешенә контрольлек итү формалары булып тора:

– дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документәлар проектларына экспертиза ясау. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

– билгеләнгән тәртиптә контрольлек тикшерүләре үткәрү;

– билгеләнгән тәртиптә Бүлектә делопроизводстсво эшләрен алып баруга тикшерүләр үткәрү;

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә үткәрелә) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы тикшерүләр үткәрелгәндә, хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгатендә күтәрелгән мәсьәлә карап тикшерелергә мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүдә агымдагы контрольлекне министр урынбасары хәл итә.

4.3. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан Регламентны үтәүгә контрольлек итү мөрәҗәгатьләрне Министрлыкка җибәрү юлы белән, шулай ук Регламентны үтәү барышында кылынган гамәлләргә (гамәл кылмау) һәм кабул ителгән карарларга югарыгы дәүләт хакимияте органнарына шикаять белдерү юлы белән хәл ителә.

4.4. Агымдагы контрольлекне хәл итүче вазыйфаи затлар исемлеге Министрлыкның структур подразделениеләре турында нигезләмәләрдә, вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозулар ачыклаган очракта гаепле затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җавапка тартыла.

## 5. Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының һәм дәүләт хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмау), шулай ук кабул иткән карарларына судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү тәртибе

5.1.Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан Министрлык вазыйфаи заты гамәлләренә яки гамәл кылмауларына Министрлыкка шикаять белдерүгә хокуклы. Министр (вәкаләтлесе) кабул иткән карарга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән, түбәндәге очракларда, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

– дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

– дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

– мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп ителгәндә;

–) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

– дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе башка норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаганда;

– дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

– Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.2. Шикаять күпфункцияле үзәк аркылы почта аша, “Интернет” челтәрен файдаланып, Министрлыкның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәй порталының яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталының рәсми сайты аркылы җибәрелергә яисә мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабу итү вакытында алынырга мөмкин.

5.3. Министрлыкка кабул итеп алынган шикаять, шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан, шикаятьне теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә, ә Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән хаталарны һәм ялгышлыкларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга шикаять белдерелгәндә – теркәүгә алынганнан соң биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

– дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме, шикаять белдерелгән гамәлләре һәм карарлары (гамәл кылмау);

– мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлар), мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслар) (булганда) һәм почта адресы;

– дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

– мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары яки гамәле (гамәл кылмау) белән килешмәвен нигезләгән дәлилләре.

5.5. Мөрәҗәгать итүче үзенең дәлилләрен раслаган документлар (булганда) яки аларның күчермәләрен тапшыра ала. Бу очракта шикаятьтә кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятькә шикаятьне тапшырган дәүләт хезмәте алучы имза сала.

5.7. Министр (вәкаләтлесе) шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

– шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәте

күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышлыкларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтелергә тиеш булмаган акча средстволарын кире кайтару рәвешендә, шулай ук башкача;

– шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм, үз теләгенә карап, электрон рәвештә, бу пунктта күрсәтелгән карар кабул итү көненнән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланмаган очракта шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи зат материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Татарстан Республикасы территориясендә
җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү
эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү һәм аны
яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү,
рөхсәтне гамәлдә булуы вакытыннан алда
туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына № 1 кушымта

**Документлар кабул итү һәм рөхсәтләр бирү үзәкләренең зоналар буенча схемасы**


| Икътисадый зона атамасы | Гаризалар кабул итү һәм рөхсәтләр бирү пункты | Икътисадый зонага керүче муниципаль берәмлекләр | Телефоны | Адресы | Эш графигы |
|---|---|---|---|---|---|
| Казан агломерациясе | Казан | Казан ш. | (843) 291-90-22, 291-91-14 | Ершов, 31А, 206 б. | сш. җом. 8.30-12.00 |
| | | Югары Ослан | | | |
| | | Лаеш | | | |
| | | Питрәч | | | |
| | Зеленодол | Зеленодол | (84371)4-84-77, 4-84-70 | Ленин, 38, 305 б. | дүш.-җом. 8.00-17.00 |
| | | Әтнә | | | |
| | | Биектау | | | |
| Идел алды икътисадый зонасы | Буа | Апас | (84374)3-11-93 | Жорес, 110, 19 б. | дүш.-җом. 8.00-17.00, обед 12.00-13.00 |
| | | Буа | | | |
| | | Чүпрәле | | | |
| | | Кайбыч | | | |
| | | Кама Тамагы | | | |
| | | Тәтеш | | | |
| Кама алды икътисадый зонасы | Арча | Арча | (84366)3-12-44, 3- | Совет мәйданы, 12, Инфраструктураны | чәр. 13.00-17.30, җом. |
| | | Балтач | | | |


| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Саба<br>Теләче | 17-44 | үстерү бүлеге | 13.00-17.30 |
| | Мамадыш | Кукмара<br>Балык Бистәсе<br>Мамадыш | (85563)3-28-82 | Җәлил, 23/33, 203 б. | дүш.-җом. 8.00-17.00, төшке аш вакыты 12.00-13.00 |
| Кама аръягы икътисадый зонасы | Чистай | Аксубай<br>Алексеевск<br>Әлки<br>Яңа Чишмә<br>Нурлатй<br>Спас<br>Чистай | (84342)5-30-50, 5-13-38 | К. Маркс, 46, 21 б. | дүш.-җом. 8.00-17.00, төшке аш вакыты 12.00-13.00 |
| Чаллы агломерациясе | Алабуга | Әгерҗе<br>Менделеев<br>Алабуга | (85557)3-81-16, | Алабуга, Тынычлык пр., 12, 123 б. | дүш.-җом. 8.00-12.00 |
| | Зәй | Зәй | (85558)3-07-19 | Крупской, 6, 73 б. | дүш.-җом. 8.00-17.00 |
| | Түбән Кама | Түбән Кама | (8555)42-40-10 | Мәктәп бульвары, 2а, 2 эт. | дүш.-җом. 8.00-17.00, төшке аш вакыты 12.00-13.00 |
| | Чаллы | Мөслим<br>Актаныш<br>Чаллы<br>Минзәлә<br>Тукай | (8552)30-56-08 | Х. Туфан, 23, 217 б. | дүш.-җом. 8.00-10.00 (гаризаларны кабул итү) дүш.-җом. 15.00-16.30 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | (рөхсәт бирү) |
| Көнъяк-көнчыгыш икътисадый зонасы | Әлмәт | Азнакай<br>Әлмәт<br>Сарман<br>Чирмешән | (8553)32-83-64, 45-38-33 | Ленин, 39, 204 б. | дүш.-җом. 8.00-17.00, төшке аш вакыты 12.00-13.15 |
| | Бөгелмә | Лениногорск<br>Бөгелмә<br>Баулы<br>Ютазы | (85594)4-00-99, 4-40-99 | Гафиатуллин, 7, 102 б. | дүш.-җом. 8.00-17.00 (гаризаларны кабул итү) сиш. 14.00-17.00, җом. 8.00-12.00 (рөхсәтләр бирү) |

Татарстан Республикасы
территориясендә җиңел таксида
пассажирлар һәм багаж йөртү
эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү һәм
аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт
дубликатын бирү, рөхсәтне гамәлдә
булуы вакытыннан алда туктату
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына № 2
кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең гамәле тәртибе Блок-схемасы (Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү)


Заявитель
Направляет заявление о выдаче разрешения с приложением документов, указанных в п.2.5 настоящего Регламента
Заявление, документы
в электронном виде через Портал государственных и муниципальных услуг РТ, по почте, лично на бумажном носителе
Специалист ИК МО
Осуществляет прием документов, регистрацию заявления в журнале регистрации заявлений, проверяет наличие оснований для отказа в приеме документов, указанных в п.2.8 настоящего Регламента
Отказ в приеме документов с указанием причин отказа
В электронном виде через портал государственных и муниципальных услуг
Заявление и документы заявителя
Специалист Отдела
Осуществляет прием документов, регистрацию заявления в журнале регистрации заявлений, проверяет наличие оснований для отказа в приеме документов, указанных в п.2.8 настоящего Регламента
Проверенные документы
при отсутствии оснований для отказа в приеме документов
при наличии оснований для отказа в приеме документов
Специалист Отдела
Направляет заявителю заказным почтовым отправлением с уведомлением о вручении или в электронной форме, в зависимости от способа подачи заявления, копию описи с отметкой о дате приема заявления о выдаче разрешения и прилагаемых к нему документов
Копия описи с отметкой о дате приема заявления и прилагаемых к нему документов
Специалист Отдела
Получает посредством системы межведомственного электронного взаимодействия в электронной форме сведения:
о статусе заявителя в качестве индивидуального предпринимателя либо юридического лица;
о поступлении денежных средств, подтверждающих оплату государственной пошлины за предоставление государственной услуги.
1 день с момента поступления заявления
Ответы на запросы
Специалист Отдела
Подготавливает проект письма о необходимости устранения нарушений и предоставления недостающих документов
Проект письма
Министр
Подписывает письмо о необходимости устранения нарушений
1 день
Подписанное письмо
Специалист Отдела
Направляет письмо о необходимости устранения нарушений и предоставления недостающих документов заявителю
1 день
Направленное заявителю письмо


Специалист Отдела
Принимает решение о выдаче разрешения или об отказе в выдаче разрешения.
Подготавливает проект приказа о выдаче разрешения или проект приказа об отказе в выдаче разрешения и уведомление с указанием причин отказа
Проект приказа
Министр
Утверждает приказ
1 день
Утвержденный приказ
Специалист Отдела
Подготавливает разрешение.
Уведомляет заявителя
Уведомление заявителя
Утвержденный приказ
Специалист отдела документооборота
Регистрирует приказ.
В случае направления заявления через районный пункт отправляет приказ в районный пункт
Зарегистрированный приказ.
Приказ, направленный в районный пункт
Уполномоченный сотрудник
Подготавливает разрешение
1 день
Подготовленное разрешение
Специалист Отдела (уполномоченный сотрудник)
Производит осмотр ТС, выдает оформленное разрешение
в день прибытия заявителя
Выданное разрешение

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү, рөхсәтне гамәлдә булуы вакытыннан алда туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затлар реквизитлары

**Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы**

| Вазыйфасы, ФИО | Телефоны | Электронный адресы |
|---|---|---|
| Министр<br>Сафин Ленар Ринат улы | 291-90-10 | Ministr.Priemnaya@tatar.ru |
| Министр урынбасары<br>Егоров Андрей Вячеслав улы | 291-90-13 | Priemnaya.02@tatar.ru |
| Транспорт идарәсе начальнигы<br>Сидоров Алексей Васильевич | 291-91-12 | Aleksey.Sidorov@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты**

| Вазыйфасы, ФИО | Телефоны | Электронный адресы |
|---|---|---|
| Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге | 264-77-01 | enter@kabmin.tatarstan.ru |